Азат Вергазов 1932 нче елның хәзерге Пенза өлкәсенең Неверкин районы Карновар авылында укытучы гаиләсендә туа.1937 нче елда гаилә Татарстанның Яшел Үзән районының Зур Карагуҗа аылына күчеп килә Азат абый шунда урта мәктәпне тәмамлап, 1949 елда Казан дәүләт педагогия институтының тарих факультетына укырга керә.Аны тәмамлап,Зур Карагуҗа урта мәктәбендә тарих һәм география укытучысы(1954-1957), Зур Яке авылында сигезьеллык мәктәбе директоры(1958-1964), яңадан үз авылына кайтып, 1970 нче елга кадәр урта мәктәптә эшли. Аннан соң Казандагы 36 нчы номерлы һөнәр училищесына барып укытып йөри. Соңгы елларда 1 нче татар гимназиясендә эшли. Якташыбыз “Аҗаган” журналының баш мөхәррире, ә аннан иҗади эш белән шөгыльләнә. 1954 нче елда шигырьләр, очерклар, һәм хикәяләр язганлыгы мәгълүм. Аларның күбесе “Идел ягы” газетасында дөнья күргәннәр.

Гомеренең иң зур өлешен яшьләргә, кеше тәрбия бирүгә багышлаган кеше буларак, Вергазов хәзерге яшьләр, ягъни безнең турында яза икән. Минемчә, бу актуаль һәм кирәкле тема саналса да, язучылар бу читерекле темага кагылырга куркалар кебек. Минем уйлавымча, аны язар өчен, шушы өлкәдә эшләргә, чын психолог булырга тиешсең. Азат абый по проблемаларда профессиональ укытучы булып эшләвен раслый, күрсәтә.

Безнең җәмгыятьнең кулында киләчәк буын. Ул- без.Тиздән мин дә укуымны тәмамлыйм. Безнең буын тотрыклымы?

Менә шушы сорауларга Азат абыйның иҗат җимешеннән җавап эзлим, һәм аның нинди күренекле шәхес булганлыгын расларга тырышам. Азат Вергазовның әсәрләре күп, ул “Ташу”, “Кайту”,”Уяну”, “Йөрәк җыр сорый”, “Без-сезнең балалар” һ.б. Бу әсәрләрдә яңа алмаш буынга уку йортларында һәм көнкүрештә дөрес әхлакый тәрбия бирү,

кешелелек,саф мәхәббәт, һәм ата-аналардан килгән күркәм традицияләрне дәвам иттерү мәсьәләләре дә күтәрелгән.

**2 нче бүлек. Азат Вергазов әсәрләре - чын тәрбия чыганагы**

“ Йөрәк җыр сорый” повестендә Азат абый кеше тормышындагы бик әһәмиятле вакыйга- яшүсмерның характерын оешып, формалашып килү моментына юнәлтелә.

Повестьның төп герое - Рәхим. Олы рухи һәм педагогик наданлыгы аркасында малай, нәкъ хәзерге заман яшьтәшләрем кебек, гаиләдән һәм мәктәптән читләшә. Әнисе Фатыйма апа улының өйдән бизүе, үзеннән читләшүе сәбәпләрен эзли. Әсәрнең беренче бите мине дулкынландырды. Фатыйма апа уйларына мин дә кушылам. Дөньяда иң якын кешеңнән шул рәвешле бизү кайдан килгән? Ни җитми ул малайга? Автор үзе дә бу вакыйганың килеп чыгу сәбәпләрен психологик яктан дәлилләргә тырыша. Рәхимнең омтылышлары бар, ләкин холыкның мөмкинчелекләре ачылмавы бигрәк тә аяныч, һәм әсәрдә моның сәбәпләре дә күрсәтелә. Фаҗига кешеләрнең бер-берсен аңлый белмәүләреннән һәм аңларга теләмәүләреннән килеп чыга. Әлбәттә,бу хәлгә төшүенә Рәхим үзе дә гаепле, чөнки малайда үтә үзсүзлелек,үпкәләүчәнлек яклары күренә -болар барысы да яшүсмерне юлдан яздыра.

Әсәрдә үз-үзләрен биттәрләгән җәфаланучылар шактый. Мәктәптән читләшүен, җинаять тозагына эләгүендә сыйныф җитәкчесе Сәвия апа да үзен гаепле саный. Үз хаталарын табып, аны төзәтә алуына ышана. Ләкин моның өчен Сәвия апага күп тырышырга кирәк була. Ул хәтта профессор Нәҗип Бәйрәмовка -баш миенең эшчәнлеген тикшерүче галимгә мөрәҗәгать итә, профессорга кызык фикер әйтә: *“Явызлык кылучы җинаятьләр бар. Гадәти тәрбия чаралары аларга көчсез. Киләчәктә шул явызлык инстинктын дәвалау медицинада кулланырмы?

Бәйрәмов кинәт урыныннан торды.

-Сез нәрсә? Бу бит кешенең шәхесен үзгәртергә маташу.

Бу җинаять .

Бу сүзләргә карата Сәвия апа кызык фикер әйтә:”Шәхесне үзгәртмичә.Шул шәхеснең үз ризалыгы белән. Алар үзләре дә үз явызлыкларыннан газап чигәләр бит.”

Әйе, Сәвия апаның җавабында дөреслек бар. Рәхим дә, төркемнең бер җитәкчесе Фаикъ дә газап чигәләр, ләкин тормыш...

Сәвия апа үзен борчыган сорауларга җавап эзли, мин дә калышмыйм. Мәктәп директоры Юныс Гыйфанович, Мәгариф бүлеге инспекторы сыйныф җитәкчесенә хаталарын төзәтергә ярдәм итә.

Укытучы үз-үзен тәнкыйтьләп, “тырышса, теләсә кем фәнне әйбәт белә ала, ә менә чын укытуы булу кыенрак. Артистлыкка укырга ничек тырышып, сынап алалар. Ә менә укытучыны нигә шулай тикшермиләр.”

Сәвия апаның сүзләре мине дә гаҗәпләндерде, аның чын укытучы икәнлеген күрсәтте. Мин шундый сүзләрдән соң аның педагогик хаталарын төзәтә алуына бөтен күңелем белән ышандым. Сәвия апа биология укытучысы буларак белә:”Әгәр тамырлары зәгыйфьләнсә, үсенте көчсезләнә, аңа яфраклары аркылы өстәмә туклану бирәләр.” Ягъни мәктәп шартларына күчереп әйткәндә, яшүсмерләрләргә игътибарны көчәйтәләр. Кызганычка каршы, Сәвия апа Рәхимгә карата боларны эшләгән икән. Менә икән Сәвия апаның гаебе .

Никадәр көч кирәк аңа моны эшләргә.Үзенә хәтта кыен булса да, яшьлегендә яраткан егете җинаять юлына баскан Фаикъ янына бара. Һәм аның ярдәмендә Рәхимне коткара, дөрес юлга кайтара. Малай әнисе янына кайта.

Рәхимгә нинди озын юл үтәргә туры килде, ә бу булмаска мөмкин идеме соң?

Бу фикер Азат Фатих улы Вергазовның "Без-сезнең балаларыгыз" дигән повестендә дә ята. Бу сүзләрне икенче укытучы -һөнәр укытучысы Нияз абый аркылы әйттерә: "Үсмер торып китәргә, тагын абынырга, ләкин тормыш корып куйган киртәләрне җиңеп барырга өйрәнергә тиеш.Үсмерләр аңында шундый омтылыш тәрбияләү- тәрбияченең төп бурычы. Ләкин бу әсәрдә дә хата ясалгач, тәрбияли белмәүнең нинди югалтуларга, фаҗигаларга китергәч, яшь буынны кешелектән чыгаргач кына нәтиҗә ясау".

Повестьнең баш герое Фәрис начар, тәртипсез гаиләдә яши. Әнисе Гөлбикә һәм әтисе Ярхәм көн-төн эчүчелек белән шөгыльләнәләр. Әти кеше төрмәдә утырып кайта, ул арада әнисе икенче кешегә, бер исереккә кияүгә чыга. Ярхәм дә яңа гаилә кора, яхшы холыклы Дания рәте-чираты бозылган бу гаиләдә тәртип салыр кебек тоела. Фәрис мәктәп-интернатны тәмамлагач, аны һөнәр училищесына урнаштыралар. Әмма инде холкы бозыла башлаган Фәрискә аз гына укытучының ишарәсе-гаеп сүзе ялгышлык та җитә кала: малай өйдән чыгып югала һәм Рәхим кебек җинаять юлына кереп китә.Фәрис талаучылар кушканны карусыз үтәп йөрүчегә әверелә.

## 3 нче бүлек. Азат Вергазов әсәрләрендә яшүсмерләр язмышлары - безнең язмышлар

"Без -сезнең балаларыгыз"повестендә якташым укучы алдында бик күп сораулар куя. Яшүсмернең киеренке хәленә төшүенә кем гаепле? Әти-әнисеме? Училищеме? Ул аннан котыла алырмы? Ни өчен 14-15 яшьтә дә яшүсмер бала булып кала? 18 гә кадәр кадәр ни өчен өлгереп җитми? Кем комачаулый? Бу катлаулы сорауларга мин дә җавап бирә алмыйм кебек. Алар тәрбияче Нияз абыйны да борчый, ләкин, минем аңлавымча, Нияз абый карашларында Азат абыйның фикерләре ята, сәбәпләрен ачыкларга тырыша.

Кечкенә баланы яслигә бирәләр, төркемдәге 30 лап баланы инкубатор чибиләредәй охшаш итә торган шартлар үзенекен итә: яңа гына формалаша башлаган шәхес югала бара. Бик ансат корылма: тәрбияче һәм төпсез масса. Мәктәптә дә шул хәл дәвам итә. Ягъни лидер плюс үз йөзен югалта барган балалар төркеме.

Макаренко ысулы дибез. Кайчандыр Нияз абый бу ысулның файдасын да күрде.Ә аның зарарлы якларына ул соңыннан гына төшенә башлады, ди язучы

## 4 нче бүлек. Азат Вергазов -чын психолог

Ә менә "Без -сезнең балаларыгыз"повестендә төркемнең үз эчендә ниләр була? Нәтиҗәдә Фәрис ни өчен төркемгә эләкте дип үз-үзенә сорау куя укытучы Нияз абый. Әйе, Фәрис үз ялгышы аркасында берүзе калды, әти-әнисе ярдәм итә алмый, укытучыны орыша. Ул япа-ялгыз яшүсмер.

Корбый һәм Сакал (лидерларның кушаматлары) -көчсезләрнең, ягъни Фәрсләрнең ярдәмчеләре .Алар чыннан да алдан күреп эш итәләр бит: башка кабатланмасын өчен, каты җәза уйлап табалар.Үтәмәгән эше өчен пассив масса Фәрескә сиеп китә, Корбый каратэ түгәрәгенең җитәкчесе дә була. Корбый башка балаларны үзенә тартып, хәтта авторитар лидерга әверелә. Галимнәр фикеренчә,мәсәлән, *Игорь Вагин, Антонина Глущай бу лидер-каты контроль һәм каты тәртип белән эш итә. Шуңа күрә Фәрис җинаятьчеләр оясын калдырып китәргә уйлый, ләкин моны булдыра алмый. Әсәрнең

ахырында бер бик гыйбрәтле эпизод бар: Фәрис пассив төркемнең бер әгъзасы (егете) белән сугыша һәм аның башына тимер чукмар белән тондыра. Хәйдәр дә җан әсәре калмаганлыгын күргәч, ул бу урынны тизрәк ташлап китә. Әмма үз-үзеннән кача алырмы соң Фәрис?

Бу сорау ачык кала. Шәхес булып калырмы? Моның өчен пассив төркем белән нишләргә кирәк? Азат абый бу сорауга җавап та бирә. “ Балаларга ирекне, мөстәкыйкьлекне бирергә, шәхес тәрбияләргә тырышырга кирәк, аларга ышанырга, шул ук вакытта үзләренә сиздерми генә кыйблаларын табарга булышырга. Җаннары нигә сусаган, нигә ашкыналар, үсмерләр шунда тапсын. Ни өчен туганнан бирле кеше кемнеңдер колына әйләнергә тиеш.Үз-үзен раслау мөмкинлеге кирәк”,-ди язучы.

Их, бу сүзләрне һәрбер ата-ана,тәрбиячеләр,укытучылар ишетсен иде. Безне, яшьләрне аңлаучы әти-әниләр, абыйлар, апалар кирәк. Азат абый бөтен дөньяга кычкырасы сүзләрне әйтә: "Кешеләрне кечкенәдән үк ирекләреннән мәхрүм итеп күренмәс пыяла өслек эченә куюны кем уйлап чыгарган? Тормыш катлаулы.Ул синең әзер рецептларың белән исәпләшеп тормый. Каршыңа бөтенләй көтелмәгән киртә корып куярга, юлыңа сикереп чыга алмаслык упкын ясап ташларга да күп сорамый.”Үсмерләрнең аңы төрле үзгәрешләр вакытында тиешле җавабын таба алырлык булып җитештелергә тиеш, ди язучы. Бик дөрес сүзләр.

**Йомгаклау**

1. Азат Вергазовның язучы буларак **с**өйләм теле төгәл, бай.
2. Яшүсмерләр тормышын шулкадәр аңлап, тирәнтен күрсәтә белгән мондый әдипләр сирәк, чын психолог, укытучы икәненә инандым.
3. Азат абыйның әсәрләрен татар халык мәкальләре белән чагыштырып, нәтиҗә ясадым:

1.

| **А.Ф.Вергазовның әсәрләреннән** | **Татар халык мәкальләреннән** |
|---|---|
| Фатыйма апа улының -Рәхимнең өйдән бизүе, үзеннән читләшүе сәбәпләрен эзли. | Баланы табуына караганда, тәрбияләү кыен. |
| Укытучы Сәвия апа:” Тырышса фәнне кем белә ала, ә менә чын укытучы булу кыенрак.” | Баланы тәрбияләү-үзеңне тәрбияләү. |
| Фәриснең әти-әнисе эчкечелек белән шөгыльләнә.<br>Малай -япа-ялгыз яшүсмер. | Улың яшьтә тәрбияче бул, улың үскәч-туган бул. |
| Корбый һәм Сакал төркеме Фәрискә сиеп китә, Фәрис- җинаятьче оясының бер әгъзасы. | Бала чагында алынмаган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да өйрәтә алмас. |

4. Якташым укытучы буларак, олыларга, бигрәк әти-әниләргә, үсмергә ирекне, мөстәкыйкьлекне бирергә, тормыш корып куйган киртәләрне җиңеп барырга өйрәнергә , моның өчен олылар комачауламаска тиеш ди.
5.Әдип психолог буларак, яшүсмер шәхес булып калсын өчен, мөмкинчелекләр булдырырга куша.

Әдип тормыштагы ак белән караның икесен дә дөрес күрә белүче. Бу табигый да. Чөнки ул 25 елга якын гомерен алмаш буынга белем-тәрбия бирүгә багышлаган.

Мин Азат Вергазовның "Без-сезнең балалар,"Дулкыннар сөйли белә"повестьларын мәктәп программасына (8-11 сыйныф укучыларына) кертергә тәкъдим итәр идем. Бәлки, безнең җәмгыять кирәкмәгән “чирләрдән” арыныр иде, ә җәмгыятьнең киләчәге-без бит. Бар сорауларыма, җавап таптым , максатыма ирештем дип уйлыйм.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1.Азат Вергазов. Без-сезнең балалар.- Казан:Аҗаган, 1996.

2. Азат Вергазов. Йөрәк җыр сорый.-Казан: Аҗаган, 1998.

3. Игорь Вагин, Антонина Глущай. Поднимись над толпой. Тренинг лидерства.- Санкт-Петербург, 2002.

4.Эрик Берн. Лидер и группа, Екатеринбург, 2001.

5. В.Т.Лисовский. Заманча яшәү ничек була?- Казан, 1996.

6. Интернет

## Сүз дигән дәрья бар

Фәнни-эзләнү эшен үтәде: 8 нче сыйныф укучысы
**Сафина Алинә.**
Җитәкче: татар теле һәм әдәбияты
укытучысы **Гайнуллин З.Р.**

Татар халкында, яхшы сүз – җан азыгы, яман сүз – баш казыгы, дигән бик мәгънәле гыйбарә яши. Теләсә нинди сүзнең көче бар, шуңа күрә дә аларның һәрберсен урынлы, дөрес итеп кулланырга кирәк. “Сүз дигән дәрья бар” дигән фәнни эшемдә мин нәкъ менә сүз белән эш итә торган һөнәр иясе – Яшел Үзән районының Айдар авылында туып үскән, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистларының “Бәллүр каләм, Хрустальное перо» конкурсы лауреаты, Халыкара, Россия һәм Татарстан журналистлары берлекләре әгъзасы, бүген “Ватаным Татарстан” газетасында баш мөхәррир вазыйфаларын башкаручы Фәния Кәбир кызы Әхмәтҗанованың журналист эшчәнлеге белән таныштырырга телим. Соңгы араларда татар теленә карата килеп туган вәзгыять шактый катлаулы. Туган телебезне яклау һәм саклау өчен журналистның каләме нәрсәләр эшләргә сәләтле? Гомумән, үз халкына, туган теленә хезмәт итүче милләтпәрвәрләр өчен нигезнең ни дәрәҗәдә нык булуы кирәк? Милләткә хезмәт итүчеләр кайда, ничек тәрбияләнә? Бу фәнни эшемнең **максаты** – әнә шушы, бүген һәр татар кешесе өчен җитди булган сорауларга җавап бирү.

**Эшемнең төп бурычлары:**

1) Фәния Әхмәтҗанова турында материал туплау .
2) Күренекле якташыбыз эшчәнлеге белән танышу.
3) Язмаларында күтәрелгән темаларны өйрәнү.
4) Журналист турында замандашлары фикерен белү.

Фәнни эшебезнең **өйрәнү объекты** – Ф.Әхмәтҗанованың тормыш юлы, иҗади эшчәнлеге.

Фәнни эшебездә өлешчә эзләнү, тикшеренү, чагыштыру, анализ кебек метод-алымнарын файдаландык.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- якташыбыз турында мәгълүмат алу;
- эшчәнлеген анализлый белү;
- әңгәмә-дискуссияләрдә катнашу, үз фикереңне әйтү;
- милли үзаң формалашу, туган төбәктә намуслы хезмәт итү теләге уяту;
- үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү.

Кем ул – журналист?

Бу сорауга җавапны гади генә, газета-журналларда, радио-телевидениеләрдә эшләүче, дип әйтергә мөмкин. Бер яктан караганда бу дөрес тә кебек. Әмма мондый ук гади аңлатма хакыйкатьне ачып бетерми.

Борынгы заманнарга күз салсак, Безнең Курсави, Мәржани, Искахый кебек галимнәребез, язучы-шагыйрьләребез дә иң беренче чиратта, бүгенге термин белән әйткәндә, журналист булган. Без бүген дә менә шушы олуг галимнәребез сүзләренә таянып, тарихыбызны өйрәнәбез, аларның эшчәнлеген өлге итеп алабыз. Чөнки журналист – ул хакимият белән халык арасындагы күпер, ягъни хакимият сүзләрен – халыкка, ә халыкныкын хакимияткә җиткерүче кеше. Әлбәттә инде, бер үк вакытта журналист күпер ролен генә үтәп калмый. Аның һәр вакыйгага үз карашы бар. Һәр темага анализ ясап, ул аналитик жанрга күчә, ягъни үз фикерен халыкка җиткерә, гаделлекне сакларга ярдәм итә.

Әлбәттә инде, журналистларның төрлесе була. Мәсәлән, газета, журнал, телевидение, радиода эшләүчеләргә аерып карарга мөмкин. Бу өлкәләрдә эшләүчеләрнең һәрберсе эш үзенчәлекләре белән аерылып торалар. Шулай ук һәр журналистның темалар төрлелеге дә күзгә ташлана. Ул гына да түгел, татар журналистикасы, гомумән, башка телдә чыккан матбугаттан үзенә хас үзенчәлекләре белән аерылып тора. Бу менталитет ничек барлыкка килә соң?

**Нигез**

Кешелек гомер бакый матурлыкка омтылган, тугрылыкка мәдхия җырлаган, фидакарьлек белән горурланып яшәгән. Бу дөньяда шушы күркәм сыйфатларның барысына да берьюлы ия булган тик бер генә зат бар: ул – хатын –кыз. Шуңа күрә тормышның кайсы да булса өлкәсен алардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Бигрәк тә журналистика өлкәсендә төпкә җигелеп тартучыларның иң – иңнәре хатын – кызлар икәнен һәрберебез яхшы аңлый. Моны нәрсә белән аңлатырга мөмкин соң? Бәлки хатын – кызның гүзәллекне, матурлыкны яратуы беләндер, бәлки бу хезмәтнең нәзакәтле, нечкә булуына, ә бәлки аларның үзләренең хезмәт җимешләре көне – сәгате белән күрәсе килүләренә бәйледер.

Сүзем - “Ватаным Татарстан” газетасының баш мөхәррир урынбасары, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге оештырган “Бәллүр каләм. Хрустальное перо” конкурсы лауреаты, күренекле якташыбыз, Айдар авылы кызы Фәния Әхмәтҗанова турында.

Ул республиканың 1918 нче елдан бирле чыгып килүче зур тарихлы, гомер-гомергә җөмһүриятебезнең рәсми матбугат чарасы булган “Ватаным Татарстан” газетасында 15 ел буе эшләп, халык арасында олы ихтирам казанган, республика җитәкчеләре хөрмәт иткән, укучылары язмаларын көтеп ала торган күренекле журналист һәм шәхесләрнең берсе.

Әхмәтҗанова Фәния Кәбир кызы Яшел Үзән районының Айдар дип аталган саф татар авылында дөньяга килә. Ул гаиләдә дә, авылдашлары белән дә саф татар телендә генә сөйләшеп үскән. Күгеш сигезьеллык мәктәбендә татарча укыган. Гомумән, ул бервакытта да туган теленнән аерылмаган. Мәктәпне тәмамлагач, кечкенәдән журналист булырга хыялланса да, Арча педагогия училищесының татар мәктәпләрендәге башлангыч сыйнфлар өчен
укытучылар әзерли торган бүлегенә юл тоткан. Монысы – Норлатта 10 нчы сыйныфны тәмамлап, университетка үтә алмасам, вакытым бушка үтәр, ә болай кулымда белгечлек булыр дигән нияттән чыгып эшләнгән. Педучилищены кызыл дипломга тәмамлагач, ул Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар журналистикасы бүлегендә белем алуын дәвам итә. Күргәнебезчә, Фәния Әхмәтҗанова гел татар дөньясында кайный. Ә гади авыл кызының журналистика дөньясына кереп китүенә нәрсә этәргеч булган соң?

Фәния Әхмәтҗанованың әнисе Хәсәнә апа авылда хат ташучы булып эшли. Газета-журналлар, посылкалар Норлаттан кич кенә кайтып җитә. Кич буе аларны, тәртипкә салып, аралап, урам буйлап өләшерлек итеп, сумкаларга тутыралар. Иртәгесен иртүк балалар төрлесе төрле якка таратырга чыгып китә. Фәниягә дә тия бу өлеш. Кичләрен ул газета-журналлар арасында актарына. Бик кызыксынып төрле язмаларны укый. Үзендә дә язып карау теләге туа. Башта “Сабантуй” газетасына яза. Аның беренче мәкаләсе чыккан газетаны авыл клубында узган ниндидер бер чара вакытында өләшәләр. Фамилиясен матбугатта күрү аны үсендереп җибәрә. Шул көннән башлап ул каләмен кулыннан төшерми. “Татарстан яшьләре» газетасына да «үрмәли”. Язарга теләге беркайчан да сүнми. Арча педучилищесында укыганда, районда чыгып килүче «Коммунизмга” газетасын үз итә. Һәм юллары аны турыдан-туры Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә илтә.

Нигезе, чыннан да, нык була Фәния Кәбир кызының. Алтынчы сыйныфка күчкәч, алар авылына татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып, Фәридә апа Әшрәпова кайта. Шул елны мәктәптә “Яшь хәбәрчеләр” түгәрәге эшли башлый. Бервакыт ул элек укыткан Карагуҗа мәктәбендә түгәрәккә йөрүче укучылары ясаган бер кочак стена газетасын алып килә. Шул көннән Фәния Әхмәтҗанова киләчәк өчен һөнәр сайлый: журналист булырга хыяллана.

Димәк, нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә. Халыкка хезмәт итүче чын милләтпәрвәрләр үстерү өчен әти-әниләргә, мәктәпкә чын җирлек тудырырга кирәк. Бала үзенең телен белеп, халкын яратып, гореф-гадәтләрен үтәп яшәргә тиеш.

**Юнәлешләр**

Әгәр дә Фәния Әхмәтҗанованың иҗатына күз салсаң, анда милләт темасы кызыл җеп булып сузылып бара.

Журналист әти-әнисе, авыл кешеләре, мәктәп еллары, укытучылары, күренекле композитор Сара апа Садыйкова, татарның беренче режиссеры Газиз Айдарский, аларның кызлары – балерина Әлфия Айдарская кебек туганнары, сабакташлары, хезмәттәшләре турында бик яратып яза. Аның язмалары аша, гомумән, милләт тарихын күзалларга мөмкин. Ул якташлары, бигрәк тә Төньяк Норлат территориясендәге авыллардан чыккан күренекле кешеләрне барлый. Аларны “Һәр якташым минем – бөек кеше” дип зурлый. Казан төрки-татар ономастикасы фәнни мәктәбенә нигез салучы Гомәр ага Саттаров, Күгеш мәктәбендә Газиз Айдарский музеен ачарга һәм күренекле авылдашыбыз турында

китап чыгарырга ярдәм иткән Госман Низаметдинов, күп еллар "Элекон заводы" ачык акционерлык җәмгыятенең башкарма директоры булып эшләгән Равил Мингалиев, ветераннар арасында берничә тапкыр дөнья чемпионы Әхмәт Сираҗиев, Татар Исламында ислам тыюлыгы булдырган Мансур Гыйлманов, татар халкының моңлы җырчысы Усман ага Әлмиев, Дәүләт премиясе лауреаты Виталий Самарцев, нәфис сүз остасы Рәшит Сабиров әнә шундыйлардан.

Милләттәшләребез турында язылган мәкаләләрнең географиясе бик киң. Бу теманы яктырту өчен Фәния Әхмәтҗанова "Ватаным Татарстан" газетасында "Син бит татар кешесе" дигән рубрика ача. Анда Россия төбәкләрендә генә түгел, чит илләрдә яшәүче татарлар турында да язмалар күп. Шунысы әһәмиятле, ул үз геройларының тормышын кайта-кайта өйрәнә, проблемаларын хәл итәргә алына, һәрдаим элемтәдә тора. Кытайда яшәүче

татарларга багышланган язмалары бигрәк тә тетрәндерә. Журналист монда, ничәмә-ничә еллар чикләр "бикле" булып торганнан соң, кайчандыр Төркестан җирләренә китеп, аннан бу җирләрнең Кытай составына керүе сәбәпле, кытай татарларына әверелгән милләттәшләребезнең тарихын яза. Шулай ук Пермь краеның Барда районында яшәүче татарлар турындагы язмаларның да әһәмияте бик зур. Ул анда бөек шагыйребез Габдулла Тукайның Зиннәтулла бабасы ягыннан булган туганнары белән дә очраша. Алар белән хәзер дә элемтәдә тора. Фәния Әхмәтҗанова милләттәшләребезнең тарихын барлау, тормышын аңлау өчен бик күп йөри. Ул булган төбәкләр арасында Березники, Пермь, Магнитогорск, Чиләбе, Озерск, Самара, Уфа кебек шәһәрләр бар. Журналист Санкт-Петербург, Омск, Оренбург, Ревда, Лангепас шәһәрләрендә Башкортстан Республикасында, Белоруссиядә, Украинада, Төркиядә яшәүче милләттәшләребез турында яза. Япониядә разведчик булып эшләгән Биби-Иран Алимова кебек исемнәре тарих төпкелендә калган милләттәшләребезне укучыларыбыз хозурына чыгара.

Фәния Әхмәтҗанованың милләтебез тормышын яктыртучы тагын бер рубрикасы бар. Ул "Кардәшләр" дип атала. Ул монда Татарстанда яшәүче башка милләт кешеләре турында бәян итә. Алар арасында әфганнар, кыргызлар, әрмәннәр, төрекләр, ахызлар һәм башка милләт вәкилләре бар. Әмма бу язмалар алар турында гына түгел. Журналист монда да бик оста алым куллана. Шушы милләт вәкилләренең Татарстандагы тормышын сурәтләгәндә, сиздерми генә аларның туган җирендә яшәп ятучы татарлар тормышына әйләнеп кайта. Шулай итеп, милләтләр арасындагы дуслык җепләрен тагын да ныгыта.

Фәния Әхмәтҗанованың иҗаты белән якыннан танышкач, мин шундый нәтиҗә ясадым: күңелен биреп эшләгән журналист милләте, халкы өчен бик күп файдалы эшләр эшли ала икән. Мәсәлән, авылдашымның Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Татар Байтуганы авылында "Әлифба" музее ачылуга зур өлеш кертүе дә - минем күзлектән караганда, зур

батырлык. Бу аңлашыла да. Алда әйтеп киткәнебезчә, Фәния Кәбир кызы Күгеш мәктәбен тәмамлаганнан соң, Арча педучилищесында белем алган. Аны анда 1962нче елда дөнья күреп, бүгенгә кадәр кулланышта булган Әлифба дәреслегенең авторы, Татар Байтуганы авылында туып үскән Сәләй Гатат улы Вәгыйзов үзе укыткан.

**Бәллүр каләм**

Журналистның эшчәнлеге күпкырлы. Шулай булмаса, ул тулы канлы тормыш белән яши алмас иде. Фәния Кәбир кызы да җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ул Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге каршында оештырылган музейны сафка бастыруда

да күп көч куя. Музей советының әгъзасы булып тора. Анда ветеран-журналистлар белән төрле очрашулар үткәрә. Күгеш мәктәбендәге Газиз Айдарский музеен оештыруда да Фәния Кәбир кызының өлеше шактый зур. Ул Арча педагогия училищесының элеккеге директоры Илдус Сәгъдиев турындагы "Күңел яктысы" исемле китапка да материаллар туплаган. "Ватаным Татарстан" газетасының 90 һәм 95 еллык юбилейларына багышлап чыгарылган китапларда да язмалары зур урын алып тора. Фәния Кәбир кызы - "Ватаным Татарстан" газетасы редакцииясендәге журналистларның башлангыч оешмасы рәисе. Ул - мөхәррир урынбасары буларак, редакциядә эшләүчеләргә генә түгел, журналист булырга теләп, университетта белем алучы студентлар өчен дә чын остаз. Шуңа күрә дә Фәния Әхмәтҗанованың күп еллар "Алтын каләм", "Бәллүр каләм" кебек Татарстан күләмендәге бәйгеләрдә, "Многоликая Россия", "ТЭФИ – Регион" кебек Россия күләмендәге конкурсларда жюри әгъзасы булып эшләве гаҗәп түгел.

Фәния Әхмәтҗанова татар журналистикасы өлкәсендә инде 30 елга якын хезмәт куя. Ул эшчәнлеген инвалидлар һәм социаль проблемалар газетасы - "Өмет" тә башлый. Аннан "Татарстан яшьләре" газетасының хатлар бүлеген җитәкли. Менә инде унбиш ел Фәния Кәбир кызы - "Ватаным Татарстан" газетасының баш мөхәррир урынбасары. Ул – Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. Күп еллык фидакарь хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән. Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге оештырган "Бәллүр каләм. Хрустальное перо" конкурсы лауреаты. Ул бик күп һөнәри бәйгеләрдә катнашкан һәм призлы урыннар яулаган.

**Йомгак.**

Минемчә, Фәния апаның эшчәнлеген өйрәнү - гади шөгыль генә түгел, ә яшәешенең төп мәгънәсе. Ул үзенең фикерен курыкмыйча, туры әйтә белүче журналист. Минем үземнең дә Фәния апа кебек үз фикеремне курыкмыйча әйтә ала торган кеше буласым килә. Ул һәр кешене ахырына кадәр тыңлап бетерә, үзенең төпле киңәшләрен бирә. Сөйләм теле бик бай. Кешене сәгатьләр буе үзенә каратып тотарга мөмкин. Мин шундый шәхесләр булуы белән горурланам, аннан үрнәк алам.

Бу фәнни эшемдә мин бик күп юнәлешләргә тукталдым. Әмма бер нәрсәнең хак икәнен исбатладым. Үз халкыңа, милләтеңә хезмәт итү өчен беренче чиратта үзеңә чын милләтпәрвәр булырга кирәк. Ә моның өчен шартлар тудыруга һәр татар кешесе үз өлешен кертергә тиеш. Авылдашым Фәния Кәбир кызы Әхмәтҗанова безнең барыбызга да әнә шул яктан өлге булып тора.

Бөек мәгърифәтчебез Ризаэтдин Фәхретдиннең бик тә кыйммәтле һәм гыйбрәтле сүзләре бар : "Әдип вә галимнәре булмаган халык бәхетсез, мәшһүр кешеләрен оныткан халык көчсез..."

Без бик тә бәхетле,чөнки әдипләребез, галимнәребез чиксез күп безнең. Олуг затларыбызны онытырга, көчсез халык булырга хакыбыз юк!

**Кулланылган әдәбият.**

1. Арча педагогия көллияте. Күңел көзгесе, 2016.- 265 б.
2. Әхмәтҗанова Ф.К. Ватаным. Казан: "Алгоритм" нәшрияты, 2018. - 416 б.
3. Ватаным Татарстан. Газетаның 90 еллыгы уңаеннан истәлекләр, документлар, фоторәсемнәр, 2008. – 220 б.
4. Ватаным Татарсан. Һич онытасым юк..., 2013, 351 б.

5. Гарифуллин В. Гаяз Исхакыйның публицистик эшчәнлеге, 2014. – 106 б.
6. Журнал “Мир бизнеса”. 100 летее Союза Журналистов Татарстана. 2018 , №2.
7. Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультеты. Милли матбугат хәзергесе һәм киләчәге, 2008. – 144 б.

**Айдарым**

Олы юлдан зәңгәр күккә ашкан
Мәчет манарасы күренә.
Күптән кайтылмады. Җирсегәнмен,
Хисләр иңри йөрәк түрендә.

Әрә таллыгында бер сандугач
Өздереп лә сайрый бәгырьне.
Син, Айдарым, Сараларың белән,
Газизләрең белән кадерле.

Кайтып җитәм инде авылыма,
Зират тавын гына менәсе...
Килә тизрәк Шәрип чишмәсенең
Салкын суын ятып эчәсе.

Әрәкәйгә яңа сулыш бирә
Карамалы, Эркә сулары.
Нинди серләр, эзләр саклый икән
Бормаланып аккан юллары.

Үлән баскан тар сукмактан менәм-
Яңа, Аръяк, Мәчет урамы...
Һәр өендә нурлы күзләр кебек
Тәрәз төбендәге яраны.

Туган нигеземә таба атлыйм -
Шаһизадә йорты, Һәдия...
Һәр авылдаш бөек кеше минем,
Җырлыйм әле сезгә мәдхия.

Әрә таллыгында бер сандугач
Өздереп лә сайрый бәгырьне.
Син, Айдарым, Сараларың белән,
Газизләрең белән кадерле.

Фәния Әхмәтҗанова



Казан дәүләт университетының III курс студентлары



Мәктәп юбилеенда укытучыларым белән



Кытайдан килгән милләттәшләребез белән



Төньяк Норлат якташлыгында кунакта




“Ватаным Татарстан”га 100 ел



Безне Урал таулары озатып калды

**Телгә тугры гомере буе...**
**Атаклы тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор**
**Фәрит Йосыф улы Йосыпов турында**

Башкарды: Сәләхетдинова Гөлназ Роберт кызы.
11 нче сыйныф укучысы
Укытучы: Хәмидова Зөлфирә Зәки кызы

Минем бу эзләнү эшем якташыбыз, Яшел Үзән районының Олы Карауҗа авылында туып-үскән атаклы тел галиме, филология фәннәре докторы, Казан Федераль университеты профессоры Фәрит Йосыф улы Йосыпов турында.

Ул Яшел Үзән районының иң күренекле шәхесләренең берсе, үз хезмәтенә фидакарьләрчә бирелгән тел галиме. Фәрит Йосыпов шәһәребез, районыбыз һәм барлык төбәкләрнең генә түгел, гомумән, татар һәм төрки халыклар язмышына бер дә битараф кала алмаган, Ватаныбызга, милләтебезгә хезмәт итүче шәхес, үз кешесе. **Фәнни эзләнүнең максаты:** Фәрит Йосыфның телебезне үстерү өстендә эшчәнлеге, иҗатының үзенчәлекләре, хәзерге көндә әһәмиятен өйрәнү.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде**:**

- Фәрит Йосыфның тормыш юлы, өйрәнү объектын ачыклау;
- телебезне өйрәнүдә хезмәте ;
- галим эшчәнлеге турында мәгълүматлар туплау, хезмәтләре белән танышу;
- галимнең тугандаш халыкларны якынайтудагы эшчәнлеге.

Эзләнү эшемне эшләгәндә аның турында күп мәгълүматлар тупладым, тормыш юлы, иҗаты, эшчәнлеге белән таныштым. Фәрит Йосыповның гаилә альбомындагы фотоларның төп нөсхәләрен күрү, үзе белән аралашу бәхетенә ирештем. Олимпиадаларга әзерләнгәндә дә, аның дәреслеге беренче ярдәмлек булып торды. Исламга багышланган “Иң изге догалар”,”Исламият” китаплары да зур кызыксындыру тудырды.

Аның турында күбрәк белгән саен, милләтебезгә армый-талмый хезмәт иткән, мәдәниятебезне, телебезне өйрәнүдә, үстерүдә зур өлеш керткән бу күренекле шәхеснең эшчәнлеге миндә горурлык хисе уятты.

Безнең мәктәп Казан Федераль университеты белән тыгыз элемтәдә торды, шул вакытларда да Фәрит Йосыпов безнең мәктәптә семинарлар оештырды, укытучыларга, укучыларга да лекцияләр укып, үткәрелгән конференцияләрдә, семинарларда, түгәрәк өстәлләрдә актив катнашты. Хәзер дә, мәдәният министрлыгында эшләсә дә, безнең мәктәп белән элемтәсен югалтмый. Әдәби тел культурасын практик үзләштерү, тормышта телебезнең мөмкинлекләрен файдалана белү, фикерне ачык, аңлаешлы, эзлекле, дөрес, төгәл итеп сөйләү күнекмәләре булдыруда ярдәм итә. Кытай Республикасыннан Казанга килеп укучы студент яшьләр белән очрашулар оештыра. Чит төбәкләрдә яшәп тә, үз телләрен, диннәрен, мәдәниятләрен саклап кала алган татар яшьләре үрнәгендә, бездә милли үзаң, телебез, мәдәният, гореф-гадәтләребезгә хөрмәт тәрбияли. Аларны Татарстанда яшәп тә үз телләрендә сөйләшергә оялып яки бөтенләй белмәүче кайбер татар яшьләренә үрнәк итеп куясы килә. Бу егет һәм кызлар үз телләрен шул дәрәҗәдә камил беләләр. Шушы яшьләрнең саф татар телендә аралашулары, йөзләрендә булган иман нуры

күңелдә ниндидер бер рәхәтлек тудыра, соклану хисләре бөтен барлыгыңны биләп ала. Әйтергә кирәк, быел бит хөрмәтле галимебезнең гомер бәйрәме дә –аңа 80 яшь тула.

**“Бар уем кичен- көндезен сезнең хакта, милләтем”**

“Син яшәсенгә яшимен, и газиз туган телем”

Фәрит Йосыпов кебек шәхесләр турында сөйләгәндә, алар халкы, милләте өчен яши һәм эшли дип әйтәләр. Аны Себер, Урал, Кырым һәм башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез үз туганнары итеп якын күрәләр. Чөнки ул бу якларда гомер кичерүче татар халкы белән аралашып, сөйләм телләрен өйрәнеп, алар турында фәнни хезмәтләр язып, аларны бөтен дөньяга таныткан, телләрен, яшәү-көнкүрешләрен ачкан галим. Ул Төркиягә юл ачучыларның берсе булып танылa. Фәрит Йосыпов, беренче булып, Татарстан балаларын Истанбулга алып чыга. Балалар андагы шартларга күнегеп җиткәнче, өчәр ай дәвамында алар белән яши. Төркия җәмәгатьчелеге безнең галимнең тугандаш халыкларны якынайтудагы хезмәтен югары бәяли, аның эшчәнлеге төрекләрнең үзләре тарафыннан хәтта Садри Максуди, Гаяз Исхакый эшчәнлекләре белән чагыштырыла. Фәрит Йосыпов, беренче эш итеп, Кырым татарлары яши торган төбәкләрне ачыклый. Баксаң, татар халкы Казахстан, Үзбәкстан һәм Төрекмәнстанда да күпләп гомер кичерә икән. Тиздән бу төбәкләрдә дә кырым-татар балалары үз телләрендә белем ала башлый, тарихларын өйрәнә. Программа-дәреслекләр, “Әлифба”лар басылып чыга. Бүгенге көндә дә Кырым татарларының зыялылары аны “туганыбыз” дип танулары юкка түгелдер.

Төрле җирләргә сибелеп утыруларыннан чыгып, татарларны дүрт төркемгә бүләләр. Беренче төркем- Татарстанда, ягъни үз республикасында яшәүче татарлар. Икенче төркем - үзләренең борынгы илләрендә, үз җирләрендә яшәсәләр дә, Татарстанга керми калганлыктан, Россия Федерациясе җирендә яшәүчеләр. Өченче төркем - татар диаспорасы, ягъни кайчандыр туган илләреннән куылган яисә «үзләре теләп» читкә китәргә мәҗбүр ителгән, ләкин элекке СССР территориясендә төпләнгән татарлар. Дүртенче төркем - чит илләрдәге диаспора, ягъни Төркиядә һәм башка илләрдә яшәүче татарлар. Фәрит Йосыпов (Фәрит Йосыф улы Йосыпов) – үзенең бөтен эшчәнлеген Россия, БДБ һәм чит илләрдә таралаган татар сөйләшләрен өйрәнүгә, татар телен балалар бакчаларында, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укытуга багышлап язылган хезмәтләре белән танылган галим. 1964 елдан башлап Фәрит Йосыпов татар теленең диалектларын һәм сөйләшләрен лингвистик география һәм ареал лингвистика методларын кулланып өйрәнү белән шөгыльләнә. Татар халкы күпләп яши торган Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Марий-Эл, Удмуртия Республикалары, Рязань, Тамбов, Нижний Новгород, Киров, Чиләбе, Свердловск, Курган. Төмән, Омск, Новосибирск, Кемерово өлкәләренә, Красноярск краена оештырылган фәнни диалектологик экспедицияләргә җитәкчелек итә. Бу өлкәләрдә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләре, халык авыз иҗаты, этнографиясе, тарихы буенча гаять бай материал туплый. Шул материаллар нигезендә күп санлы фәнни мәкаләләр, монографияләр бастырып чыгара. Бу сөйләшләрнең формалашу тарихы, аларның фонетик системалары, грамматик төзелешләре, лексик байлыклары галимнең "Көнъяк Урал Һәм Урал арты сөйләшләре", "Татар диалектлары. Урал сөйләшләре", "Красноуфим татарлары: тарих, тел, фольклор" , “Сафакүл татарлары: тарих, тел, Халык авыз иҗаты” дигән һ.б монографияләрендә дә киң яктыртыла. Әлеге монографияләрдә Урал географик зонасында таралган красноуфим, нократ-кистем, эчкен,

нагайбәк, сафакүл сөйләшләренең формалашулары әлеге этник төркемнәрнең барлыкка килүләре белән тыгыз бәйләнештә карала. Моның өчен автор бай лингвистик әдәбияттан тыш архив материаллары, тарихи чыганакларга да мөрәҗәгать итә. Әйтергә кирәк, бу материалларның күбесе фәнни әдәбиятта беренче буларак кулланылышка кертелә. Югарыда аталып киткән монографияләр лингвистик география методы белән беррәттән системалы - синхрон методларны кулланып язылганнар.

Фәрит Йосыповның 8 китабы мәктәп, балалар бакчасы өчен; 16 китап исламга багышланган; фәнни китаплары белән 50 ләп китабы басылып чыккан. "Морфология татарского диалектного языка" дигән монографиясе Россия филология фәненә зур яңалык алып килде. Хезмәт татар диалектология фәненең ирешкән үрләре турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Монографиядә кулланылган яңа методлар, галим ясаган нәтиҗәләр, төрки телләр алдында торган катлаулы мәсьәләрне хәл итүдә уңышлы кулланылып, төрки телләрне һәм аларның диалектларын төркемләүдә ышынычлы нигез булып торачак. Монографиянең уңай якларын исәпкә алып, Россия Мәгариф һәм фән министырлыгы каршындагы филология буенча укыту-методик берләшмәсе "Морфология татарского диалектного языка" дигән монографиясен Россия Федерациясенең классик университетларының милли бүлекләре өчен дәреслек буларак тәкъдим итте. Галимнең әлеге һәм башка монографияләре Казан дәүләт университетында гуманитар фәннәр арасында үткәрелгән конкурста иң яхшы фәнни хезмәтләре дип табылды.

Фәрит Йосыповның 602 битле”Татар диалект теленең морфологиясе” китабы Төркиядә төрек телендә дә басылып чыкты. Төркиядә 190 университет бар, шуның 80 ендә татар теле укытыла. Бу китап студентларның дәреслеге итеп кабул ителде. Ул төрек студентларына татарлар, татар теленең сөйләм үзенчәлекләре турында өйрәнеп, күп мәгълүматлар тупларга мөмкинлек бирә. Казан татарлары һәм Татарстан исеме астында Төркиянең Елазыг шәһәрендә бу китапның, бик зурлап, презентациясе үткәрелде.Тауларның артында Сирия, татар теле Сирия һәм Ирак чик буйларына килеп җитте, дип горурланып әйтә алабыз. Татарстанда фән, мәдәният торышы турында да сөйләшүләр була. Фәрит Йосыпович гомере буе милләт өчен тугры хезмәт итә, телне таныту өстендә армый – талмый эшли. Ул”Төрек һәм ислам дөньясының бөек шәхесләре” темасына Төркиядә үткәрелгән хаыкара конференциядә Садрый Максудый турында, аны танытып, зур чыгыш белән катнашты.

Туган авылы Карауҗа халкы да аның белән нык горурлана. Һәр елны диярлек очрашулар үткәреп тора. Аның хөрмәтенә “Син яшәсенгә яшимен, и азиз туган телем” исемендә очрашуда бу китапның презентациясе дә булды. Фәрит абый үзенең туган авылында очрашу оештырылуга чиксез шат булуын әйтте. Кайларда гына йөрсә дә, Карауҗа малае булуы белән горурлануын яшермәде һәм туган туфракның һәрвакыт үзенә тартып торуы аның өчен зур куаныч булуын әйтеп үтте. Аның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында чыгышлар булды, авыл халкы, килгән кунаклар аның хөрмәтенә зур концерт та күрсәтте. Әйе, халык үз улын олылый, димәк үз үткәненә хөрмәтен, киләчәккә лаек булуын раслый. Ул һаман хезмәттә. Аның Новосибирски татарлары турында “Барабар татарлары” дигән китабы басылуга хәзерләнеп ята. “Сафакүл татарлары. Тарих, тел, халык иҗаты” китабының икенче томының яңа гына дөнья күрүе дә аның зур хезмәт җимеше. 2018 нче елда 4 томлык “Себер татарларының рухи мәдәни җәүһәрләре”дигән китабы басылып чыкты. Беренче томда - дастан, мөнәҗәтләр, бәетләр; икенче томда йоматы, әкитләр; өченче томда хикәят, легенда,риваятьләр; дүртенче томда музыкаль мирас тупланган.

Тагын дәвамы итеп күздә тотылган алты том өстендә эшли галимебез.Шуның өстенә, Төркиядә чыккан журналларда төрек, инглиз телендә мәкаләләре дә асылып тора. Апрель, октябрь айларында "Татар теленең ореал лингвистикасы" дигә темага фәнни конференциядә чыгышлар ясарга әзерләнә, югары уку йортларында лекцияләр укый. Милләт хәтерендә онытылмаслык эз калдыра торган, халыкның хәтер-күңел хәзинәсендә күренекле урын алган, халыкның тел белемен баеткан мәртәбәле шәхес ул. Ул дөнья күләмендә сибелгән халкыбызны берләштерү, туган телебезне, милли мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклау буенча да зур эшләр башкаручы.

**Үз халкыңа хезмәт итү генә, зур дәрәҗәләргә илтә**.

" Кеше турында сөйләгәндә аны шәхес иткән сыйфатлар турында әйтмәсәң, тулы картинаны биреп булмас иде. Фәрит Йосыпович – киң күңелле, кунакчыл. Ул – оста оратор һәм хикәяче. Аның сөйләгәннәрен сәгатьләр буе армыйча тыңлап була. Бер кешеме, тулы бер залмы – әһәмиятле түгел. Ул – дуслаша, дуслыкка тугрылыклы. Аның дуслары арасында чал чәчле аксакаллар да, яшь егетләр дә бар. Ул аларның барысын да тигез һәм тиң күрә. Кирәк вакытында кырыс та була белә, кирәк вакытында синең күңелеңне күтәрә һәм, иң әһәмиятлесе, кешенең күңелен үстерә белә. Ул яхшы ата һәм гаилә башлыгы, оныкларын яратучы бабай,"-ди аның турында Олег Хисамов, филология фәннәре кандидаты, доцент. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының директор урынбасары.

Фәрит Йосыпов Татарстанда (алай гына түгел, хәтта татарлар күпләп яши торган башка төбәкләрдә дә) милли балалар бакчалары, мәктәпләр ачу, татар балалары укыган рус мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен кертү буенча гаять нәтиҗәле эшчәнлек алып бара.Татар тел белеменең күп төрле тармакларында, халык мәгарифе, фольклор, этнография, педагогика һәм методика фәннәре өлкәсендә җиң сызганып эшләүче галим, монографияләр, балалар бакчалары, урта мәктәпләр өчен программа һәм дәреслекләр, уку әсбаплары авторы, соңгы елларда дини китаплар чыгаручы. Йосыпов– ислам динен халкына җиткерү өлкәсендә дә күп көч куйган кеше. Аның дин өлкәсенә караган китаплары бүген дә актуальлеген югалтмый. Аларда ислам тәгълиматлары гади, кеше аңларлык итеп бирелә. Хезмәтләре өчен, профессор Фәрит Йосыпович Йосыпов «Намуслы хезмәт өчен»дигән Д.М.Ушинский исемендәге медальләр белән бүләкләнде. Ул – Россиянең мәгариф отличнигы, Бөтенроссия укытучылар съезды делегаты. Галимебез – Тюркологлар комитеты, Шәрыкне өйрәнү ассоциациясе әгъзасы, Казан дәүләт университетында, Россия милли мәктәпләр институтында, Дагыстан педагогия университетында кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советлары әгъзасы, Диния Нәзарәтендә дә ниндидер комиссияләргә керүче Фәрит Йосыповның исеме бөтен татар кешесенә якын һәм таныш. Профессор Фәрит Йосыпов Кебридж биография үзәк энциклопедиясенең "хх нче гасырның иң күренекле кешеләре" исемлегенә кертелгән. Фәрит Йосыповның экспедициягә чыкмаган берәр елы бармы икән?! Яше олы булуга карамастан, профессор ел саен егермешәр көнлек экспедицияләргә чыгуын дәвам итә. Халык авыз иҗатын, тел үзенчәлекләрен җыю серләрен яшь буынга өйрәтә. Ул бөтен Себерне, Курган, Чиләбе, Свердловск, Оренбург өлкәләрен, Башкортстан, Марий Иле республикаларын, Пермь, Киров, Әстерхан өлкәләрен студентлар белән дә, ялгыз гына да әйләнеп чыга. Без, яшьләр, шундый галимебез булуы белән горурланабыз. Милләтне, аның телен саклап калу өчен безнең арадан да, һичшиксез, галимебезнең эшен дәвам

итүчеләр чыгарга тиеш. Аның быел гомер бәйрәмен 80 яшь тула. Аңа исәнлек, саулык телик.

Файдаланган әдәбият

1.”Балалар бакчасы”-уку китабы, Казан.” Раннур”нәшрияты,2003.
2. Исламият.- Казан. Раннур
3. Иң изге догалар. –Казан: Раннур
4. Кто есть кто. –Казан: Мәгариф, 2002.
5. Казанская лингвистическая школа. –Казань: Тат. кн. Изд-во., 2008
6. Мәгариф, 1999. №4
7. Мирас. 1999, №5.
8.Рус мәктәпләренең 2-4 сыйныфларында татар теле укыту. –Казан.2005
9.Сафакүл татарлары. Тарих, тел, халык иҗаты. –Казан, 2006
10. Татар теленең диалектлары. Урал сөйләшләре. –Казан: Мәгариф, 2003.
11.Татар теле. 6нчы сыйныф. –Казан: Мәгариф, 1999.

**Тормыш юлы һәм иҗаты.**

Фәрит Йосыпов 1939 елның 15 маенда Татарстан Республикасының Зеленодол районы Зур Карауҗа авылыныда туа.

Зур Карауҗа урта мәктәбен тәмамлый.

1956 – 1961 елларда Казан дәүләт университетының тарих – филология факультетында укый.

1964 елдан башлап Фәрит Йосыпов татар теленең диалектларын һәм сөйләшләрен лингвистик география һәм ареал лингвистика методларын кулланып өйрәнү белән шөгыльләнә.

1972 елда "Көнъяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре" дигән темага кандидатлык.

1989 елда "Татар фигыльләрен ареал ысул белән өйрәнү" дигән темага докторлык диссертацияләрен яклый.

Фәрит Йосыпов фәнни эшчәнлеген СССР Фәннәр Академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр буларак башлап җибәрә.

Кама Тамагында чыга торган “Кызыл байрак” газетасының җаваплы сәркатибе булып эшли.

1972 – 1984 елларда Алабуга педагогия институтында чит телләр факультеты деканы.

1984 – 1995 елларда Татарстан Милли мәктәпләр институтының директоры булып эшли.

Берничә ел Төркия университетларында һәм Төркия Чит илләр министрлыгында эшли.

1995 елдан – Фәрит Йосыпов Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультетының укыту методикасы һәм хәзерге татар әдәбияты кафедрасы профессоры.

Яшел Үзәндә Казан дәүләт университетының филиалы ачылгач та, галим анда татар теле һәм әдәбияты бүлеген оештырып җибәрә һәм озак еллар аның белән җитәкчелек итә.

Фәрит Йосыпович бүген дә филиалда якташларына белем бирә. Яшел Үзән мәктәпләрендә фәнни консультант булып тора.

Профессор хәзер дә ел саен егермешәр көнлек экспедицияләргә чыгуын дәвам итә.

2015 нче елдан мәдәният министрлыгының традицион мәдәни үстерү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре




Атаклы тел галиме, филология фәннәре докторы, Казан Федераль университеты профессоры Фәрит Йосыф улы Йосыпов





Бүгенге көндә дә татар халкы күпләп яши торган Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Марий-Эл, Удмуртия Республикалары, Рязань, Тамбов, Нижний Новгород, Киров, Чиләбе, Свердловск, Курган. Төмән, Омск, Новосибирск, Кемерово өлкәләренә оештырылган фәнни диалектологик экспедицияләргә җитәкчелек итә.



Фәрит Йосыповның 602битле “Татар диалект теленең морфологиясе” китабы Төркиядә төрек телендә дә басылып чыкты. Төркиядә 190 университет бар, шуның 80 ендә татар теле укытыла, бу китап төрек студентларының дәреслеге итеп кабул ителде. Төркиядә, китап презентациясеннән мизгелләр…













**Тауларның артында Серия.Татар теле шушы Серия һәм Ирак чик буйларына килеп җитте**




